**Казан федераль университеты**
**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы**
**Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты**

**Н.М. ЙОСЫПОВА**

# ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА УКУЧЫЛАРНЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДАГА ӘЗЕРЛӘҮ

**Методик кулланма**

**КАЗАН - 2025**

Методик кулланма Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында үткәрелгән «Идел буе республикаларының милли әдәбиятлары: мәдәниятара багланышлар мәсьәләләре» халыкара конференциясе кысаларында эшләнде

**Автор һәм төзүче**: филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар әдәбияты кафедрасы профессоры **Н.М. Йосыпова**

Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны татар әдәбиятыннан олимпиадага әзерләү (методик кулланма) / Н.М. Йосыпова. – Казан, 2025. – 28 б.

Әлеге методик кулланма татар әдәбиятыннан олимпиадага әзерләнү юлында укучы һәм укытучыларга юнәлеш бирү максатын күздә тота. Ул олимпиада биремнәрен тәкъдим итү белән беррәттән, аларны башкару өчен ярдәмгә килерлек методик киңәшләр белән тулыландырылган.

Кулланма татар әдәбиятыннан олимпиадага әзерләнүче укучыларга, мөгаллимнәргә һәм, гомумән, татар әдәбияты белән кызыксынучыларга йөз тота.

© Йосыпова Н.М., 2025

# КЕРЕШ

Гомуми белем бирү оешмаларының 5-11 сыйныф укучыларына, укытучыларга йөз тотып төзелгән әлеге кулланманың төп максаты – укучыларның белемнәрен системага салырга ярдәм итү, татар әдәбиятыннан олимпиаданың мәктәп, муниципаль һәм республика этапларына мөстәкыйль әзерләнергә юнәлеш бирү. Әлеге юнәлештәге кулланмаларга ихтыяҗның көчле булуы һәм соңгы елларда мондый типтагы хезмәтләрнең басылмавы методик басманың актуальлеген билгели.

Кулланманың беренче бүлеге методик материалны колачлый, аның беренче өлешендә үткән олимпиада нәтиҗәләренә күзәтү ясала, икенче өлешендә киләчәктә олимпиадага әзерләнү барышында ярдәмгә килердәй методик киңәшләр һәм җавапларга таләпләр урын ала, укучы һәм укытучыларга юнәлеш бирелә. Моннан тыш иҗади һәм язма биремнәрне башкаруга кагылышлы киңәшләр дә тәкъдим ителә.

Методик кулланманың икенче бүлегендә агымдагы уку елында үткәрелгән мәктәп һәм муниципаль турларның һәм узган уку елындагы республика турының сорау һәм биремнәре тәкъдим ителә. Әлеге олимпиада сораулары аша укучыларда гомуми күзаллау, система, киләсе бәйгеләргә әзерлек юнәлешен булдыру күздә тотыла.

Күренгәнчә, сезнең кулыгызга килеп кергән әлеге кулланма шактый киң материалны колачлый. Шул яктан ул гомуми белем бирү оешмаларында укучы һәм укытучылар өчен гаять файдалы булыр дип уйлыйбыз.

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК.
## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА: БИРЕМНӘРНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ ҺӘМ ӘЗЕРЛӘНҮГӘ БӘЙЛЕ МЕТОДИК КИҢӘШЛӘР

Туган (татар) әдәбияттан олимпиада өч этаптан тора: мәктәп туры, муниципаль этап һәм республика этабы. Әлеге этапларда биремнәр дә җиңелдән авырга принцибына нигезләнеп төзелә. Татар әдәбиятыннан олимпиаданың һәр этабы берничә максатны күздә тотып үткәрелә. Беренчедән, балаларның татар әдәбиятыннан белем дәрәҗәсен, иҗади фикерләү үзенчәлеген, калыбын ачыклау; икенчедән, республика белем бирү оешмаларында татар әдәбиятын укытуның торышын билгеләү; өченчедән, мәктәпләрдә гамәлдә йөргән программа һәм дәреслекләрнең ни дәрәҗәдә таләпләргә туры килүен төгәлләштерү, дүртенчедән, һәм иң мөһиме, балалар арасыннан аеруча сәләтлеләрен сайлап алу.

Әлеге максатлар сорауларның укучының әдәби иҗатка һәм әсәргә анализ ясау мөмкинлекләрен, аның китап уку, әдәбият белән кызыксыну, логик фикерләү дәрәҗәсен ачык күрсәтеп торырга тиешлеген дә нигезли. Шуңа да туган (татар) әдәбияттан олимпиаданың һәр турына тәкъдим ителгән сораулар һәм биремнәр, гомуми характерда булудан бигрәк, укучыларның нәзари (теоретик) белемнәрен, әдәби барышны, шул процесста билгеле урын токкан әдипләрнең иҗат үзенчәлекләрен бәяләү, әдәби әсәр белән эшләү мөмкинлекләрен, әсәрне аңлау дәрәҗәсен, шәхси фикерен, иҗади сәләтен ачыклау максатын күздә тотып эшләнә.

Хәзерге вакытта туган (татар) әдәбият ФДББСна нигезләнеп төзелгән яңа программа һәм дәреслекләр нигезендә укытыла. Шуңа да быел олимпиадаларга сораулар төзү барышында бу як исәпкә алынды, ягъни һәр сыйныфка үзе укый торган яңа программа һәм дәреслеккә нигезләнеп төзелгән биремнәр тәкъдим ителде.

Ләкин шунысын да ассызыклап үтәргә кирәк: олимпиадага, аеруча республика турына сораулар төзү барышында дәреслек һәм программалар

белән чикләнеп калынмый. Чөнки республика күләмендәге бәйге мәктәп һәм муниципаль турлардан үтеп килгән иң көчле, әдәбият белән кызыксына торган, әдәби процесстан мәгълүматлы, фикерле балаларны үзенә җыя. Сорауларның да мәктәп дәреслеге кысаларында гына калмыйча, бәйгедә катнашучының әдәбият белән мөстәкыйль кызыксынуын, иҗади фикерләү мөмкинлекләрен, узган елларда үтелгән материалны ни дәрәҗәдә истә калдыруын да ачыклавы мөһим. Шул критерийлар нигезендә республикада сораулыклар төзүнең билгеле бер калыбы эшләнгән һәм системага салынган. Аерым бер әсәрнең яки әдип иҗатының үзләштерелү дәрәҗәсен, укучының иҗади һәм логик фикерләү югарылыгын, теоретик базасын, теге яки бу әсәргә шәхси мөнәсәбәтен, карашын җиткерү осталыгын бәяләү-тикшерү төп максатлар буларак билгеләнә.

Олимпиада сораулары һәм биремнәре берничә аспектны күздә тотып төзелә. 5-8 нче сыйныфларда аерым бер әсәрнең яки әдип иҗатының үзләштерелү дәрәҗәсен, укучының иҗади һәм логик фикерләү югарылыгын, теоретик базасын, теге яки бу әсәргә шәхси мөнәсәбәтен, карашын җиткерү осталыгын бәяләү-тикшерү төп максатлар буларак билгеләнә. 9-11 нче сыйныфларда исә аерым бер дәвер әдәбиятының үсеш үзенчәлекләренең, әдип иҗатының үзләштерелү дәрәҗәсен, укучының иҗади һәм логик фикерләү югарылыгын, әсәргә анализ ясау дәрәҗәсен, теоретик базасын, теге яки бу әсәргә шәхси мөнәсәбәтен, карашын җиткерү осталыгын бәяләү-тикшерү төп максатлар буларак куела.

Теоретик блокка караган сорауларга укучылар, нигездә, дөрес җавап бирә, әдәби әсәрнең исемен, нәзари төшенчәне төгәл билгели, тест сорауларына төгәл җавап бирә ала. Шунысы куанычлы: “авыр” дигән ярлык тагылып, һәрвакыт укучыларны куркытып торган теоретик төшенчәләр укучылар тарафыннан дөрес билгеләнә, тест рәвешендә бирелгән теоретик биремнәр укучыларда авырсыну тудырмый. Шул ук вакытта теоретик биремгә төгәл билгеләмә язу яисә теоретик төшенчәнең сыйфатларын аерым әсәргә бәйле аңлату юнәлешендәге сораулар укучылар тарафыннан авыррак

кабул ителә.

Аерым әдип иҗатына яки әдәби әсәргә бәйле блокка караган җаваплар укучыларның әдипләр иҗатыннан  һәм әсәрләреннән шактый мәгълүматлы булуын күрсәтә. Билгеле, 5-8 сыйныфларда 2-3 җөмлә күләмендә генә җавап язган яки, гомумән, җавапсыз калган эшләр дә очрый. Югары сыйныфларда мондый биремнәр авырлык тудырмый диярлек, бары тик җавапларның тирәнлеге, әсәрләргә нигезләнеп язылу дәрәҗәсе генә төрлечә була. Бу исә мәктәптә әдипләр иҗатының, әдәби әсәрләрнең шактый җентекле өйрәнелүе-бәяләнүе турында сөйли.

Укучылар өчен иң кыенлык тудырган биремнәр иҗади блокка карый. Бу биремнәргә, кагыйдә буларак, барлык балалар да җавап яза, әмма аларның таләпләргә туры килү дәрәҗәсе шактый төрле була. Укучыларның күбесе күрсәтелгән темага гомуми характердагы язма тәкъдим итә, билгеләнгән образны детальләп һәм аллегорик сурәтли алган эшләр, кызганычка каршы, күп очрамый.

Шунысы үзенчәлекле: олимпиада сорауларына язылган җаваплар укучыларның бүгенге әдәби барыштан артык мәгълүматлы  булмавын күрсәтә, хәзерге вакытта актив иҗат эше белән шөгыльләнә торган әдипләрне билгеләү алар өчен шактый кыенлык тудыра. Китерелгән җавапларның да күбесе мәктәп дәреслекләрендә урын алган яисә 1960-80 елларда актив иҗат иткән әдипләр белән чикләнә. Бу исә укучыларның вакытлы матбугат, әдәби китаплар белән артык «дус» булмавын күрсәтә.

Укучыларны туган (татар) әдәбияттан олимпиадага әзерләү барышында түбәндәге мәсьәләләргә игътибар юнәлтү мөһим:

1. Теоретик төшенчәләрне, матералны кабатлау. Укучыларның нәзари  төшенчәләрне аңлау дәрәҗәсен ачыклауны күздә тоткан теоретик юнәлештәге сорау алар өчен авыр булып санала. Укучы теге яки бу теоретик төшенчәгә бәйле тестка бик тиз җавап бирә ала, аеруча ябык тестларга җавап бирү алар өчен бөтенләй дә кыенлык тудырмый. Ә киңәйтелгән җавап язуга йөз тоткан бирем укучыларның бу юнәлештәге белемнәре шактый төрле

икәнлеген күрсәтә. Балалар коры билгеләмәне генә язып куюдан тыш, аның төп сыйфатларын әсәрләрдән мисаллар нигезендә дәлилли алырга да тиеш. Моның өчен олимпиадага әзерлек барышында укучы программада күрсәтелгән нәзари (теоретик) төшенчәләрне дәреслектән тагын бер кат карап чыгарга, күңеленә сеңдерергә тиеш. Моннан тыш белемнәрне «Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге», «Татар әдәбияты. Теория. Тарих», «Татарча-русча-инглизчә әдәбият белеме терминнары сүзлекчәсе», «Татар әдәбияты таблицаларда», «Әдәби нурлар» кебек методик хезмәтләрдән файдаланып тирәнәйтү дә кирәк.

2. Икенче блокта аерым бер әдип иҗатына һәм әсәргә төрле яклап бәя бирү, бу очракта аның үзенчәлеген, теге яки бу әсәрнең тема-проблемасын билгеләү, образларга характеристика бирү, вакыйгаларга бәя бирү, автор позициясен ачыклау алга куела. Мондый сораулар төгәллекне, теоретик материалны белеп һәм дөрес куллануны сорап тора.

Иң беренче чиратта әдәби әсәрләрне кабат укып чыгу, тәнкыйди материаллар белән танышу, алар турында шәхсән уйлану киңәш ителә, чөнки җавапларда дәреслек материалын ятлап керү генә үзен акламый. Иң мөһиме: җаваплар укучының, дәреслек материалына һәм тәнкыйди язмаларга таянып, үз шәхси бәясен, фикерләү дәрәҗәсен чагылдырырга тиеш. Икенчедән, мондый сорауларга җаваплар барышында билгеләнгән язучы, шагыйрь яки драматургның тормыш юлындагы төп фактларга, эшчәнлегенең төрле якларына тукталып, иҗатында ул күтәргән төп тема-проблемаларны, еш мөрәҗәгать иткән образларны, аларның төрләрен, иҗат юнәлешен, сүз сәнгатенә алып килгән яңалыгын ассызыклап бару отышлы. Бу аеруча югары сыйныфлар өчен мөһим. Һәр фикер шул конкрет фактлар, әсәрдән мисаллар, фрагментлар белән ныгытылган булса, нур өстенә нур булыр, шуның өстенә язучының стилен, төп иҗади сыйфатларын бәяләү шул дәвердәге әдәби-тарихи контекст белән бәйләп алып барылса яхшы бәяләнә. Әдәби иҗатка һәм әдәби әсәргә бәя бирү схемасы «Әдәби нурлар»ның 3 кисәгендә тәкъдим ителә. Укучылар шушы схема нигезендә бәя биреп баруга күнексә,

олимпиада вакытында да мондый типтагы сорауларга җавап язу алар өчен кыенлык тудырмаячак.

3. Өченче блок сораулар югары сыйныфларда билгеләнгән дәвер татар әдәбиятына, әдәби процесска бәя бирүгә, аларның төп үсеш үзенчәлекләрен, сыйфатларын аерып алуга, билгеләүгә йөз тота. Мондый сораулар укучыдан күрсәтелгән вакыт аралыгында әдәбиятның төп сыйфатларын, үсеш-үзгәреш закончалыкларын, үзенчәлекләрен аерып чыгаруны таләп итә. Әзерләнү барышында һәр әдәби чорның төп үзенчәлекләрен төгәл итеп аерып чыгару һәм дәфтәргә теркәп бару мөһим. Моннан тыш һәр әдәби чорда актив иҗат иткән әдипләр, аларның әсәрләре дә укучы игътибарыннан читтә калмасын иде. Әдәбият тарихының аерым чорлары, шул чор сүз сәнгатенең үзенчәлекләре хакындагы белем дә системалы түгел, укучылар еш кына әдәби чорларны бутарга яки эзлекле тәртиптә күзалламый. Әдәби чорга бәя бирү схемасы «Әдәби нурлар»ның 3 кисәгендә урын ала. Укучылар әдәби чорларга шушы схема нигезендә анализ ясауга күнексә, олимпиада биремнәренә җавап язу да куенлык тудырмас дип ышанабыз.

4. Әдәби әсәргә анализ ясау күнекмәләрен дә камилләштерү мөһим. Мондый биремнәрдә төрле әдәби төр һәм жанрга кагылышлы әсәрләр тәкъдим ителеп, тулы анализны күздә тотмыйча, теге яки бу теоретик төшенчә белән бәйләнештә бирелгән булырга (образлылык ягыннан, тел-сурәтләү чаралары ягыннан һ.б. төрле анализ) яки әсәргә анализ ясагыз дип кенә куелган булырга да мөмкин. Шулай да олимпиада биремнәренә шигырь анализының ешрак тәкъдим ителүе дә сер түгел. Бу, иң беренче нәүбәттә, шигырь текстын уку өчен вакытның аз сарыф ителүе, әдәби текстның укучы алдында тору мөмкинлеге белән бәйләнгән. Бу сорауга җавап күрсәтелгән әсәрне, теоретик материалны яхшы, җентекле белүне сорап тора.

Анализга кагылышлы биремнәргә җавап эчтәлек сөйләүгә кайтып калырга тиеш түгел, авторның әйтергә теләгән фикерен, үз караш-мөнәсәбәтеңне ачыклау мөһим. Укучылар өчен анализга мөнәсәбәтле сорау

иң авыры булып кала, бу юнәлештәге җаваплар төгәллек җитмәве, эзлексезлеге белән аерылып тора. Эпик, лирик һәм драма әсәрләренә анализ ясау схемасы «Әдәби нурлар»ның 3 кисәгендә тәкъдим ителә. Олимпиадаларга әзерләнү барышында укучыларны шушы схемага нигезләнеп җавап язуга күнектерү кирәк.

5. Иҗади бирем олимпида эшенең бер блогын тәшкил итә, шуңа да укучы өчен иң мөһиме: вакытны тигез бүлеп, аннан уңышлы файдалану, моның өчен укучы әзерлек барышында ук шушы вакыт аралыгына сыешырга күнегергә тиеш. Иҗади биремгә ныклап әзерләнү сорала. Мондый биремнәр укучының әдәбиятны аңлау дәрәҗәсен генә түгел, логик фикерләү куәсен, фантазиясен, иҗади мөмкинлекләрен, иҗади эрудициясен дә ачарга ярдәм итә. Укучыга төрле жанрда иҗади эш язып, үз көчен, сәләтен сынап карарга урын калдыра. Мәсәлән, берәр мәкаль-әйтемгә таянып, геройга характеристика бирү; тәкъдим ителгән темага хикәя, инша язу һ.б. Мондый биремнәргә җавап язу барышында укучылар үзләренең иҗади фикерләү куәсен күрсәтергә тиешләр чөнки бәяләү барышында нәкъ менә иҗади фикерләү ягына басым ясала.

Татар әдәбиятыннан олимпида биремнәрен башкару юлында иң мөһиме: җаваплар укучының, дәреслек материалына һәм тәнкыйди язмаларга таянып, үз шәхси бәясен, фикерләү дәрәҗәсен чагылдырырга тиеш. Җаваплар озын булмыйча, төгәл һәм тәмамланган фикерләрдән торса яхшы. Биремнәрдәге һәр сорауга төгәл, дәлилле җавап югары бәяләнә.

Мәктәп, муниципаль һәм республика турларына тәкъдим ителгән сорауларга һәм биремнәргә тукталыйк.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК.
## ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА УКУЧЫЛАР ӨЧЕН ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ РЕСПУБЛИКА ТУРЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ
## (2024-2025 УКУ ЕЛЫ)

### VII СЫЙНЫФ

**I бүлек. Тест биремнәренә җавап языгыз (24 балл).**

1. Әдәби әсәрдә конфликтны барлыкка китерүче сәбәпләр, аның алшартлары белән таныштыру (1 балл):

1) төенләнеш
2) экспозиция
3) эпилог

2. Әдәби әсәр тудыруда катнашып, геройның бер сыйфатын ачарга ярдәм итә торган, язучы аерым игътибар иттергән, җентекләп күрсәткән әйбер, хәрәкәт, төс (1 балл):

1) символ
2) әйбер образлары
3) деталь

3. Читләтеп әйтүнең бер формасы, күренеш-хәлләрне предмет-сурәтләр белән атау (1 балл):

1) метафора
2) аллегория
3) символ

4. Әсәрнең эмоциональ көйләнеше, язучының фикерен җиткерү өчен сайланган хис яңгырашы (1 балл):

1) оксиморон
2) хис-кичереш
3) пафос

5. Бер кешенең сөйләме, үз-үзенә сөйләве (2 балл):

Җавап: ____________________

6. Сюжет сызыклары лирик чигенешләр, хис-кичереш һәм мөнәсәбәт белдерү белән үрелеп баручы, әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләр күтәрә торган лиро-эпик жанр (2 балл):

Җавап: ____________________

7. Аерым детальләр ярдәмендә табигатьнең бер күренеше образга әйләндерелгән, табигать сурәте тудырылган шигырь (2 балл):

Җавап: ____________________

8. Кече эпик жанр, катлаулы булмаган вакыйганы, кешенең билгеле бер сыйфатын ача, тормышның аерым бер мизгелен генә алып тасвирлый (2 балл):

Җавап: ____________________

9. Кешене хәрәкәттә, каршылыкларда күрсәтүгә һәм шунда геройларның холык-фигыльләрен ачуга юнәлтелгән әдәби төр (2 балл):

Җавап: ____________________

10. *Татар халык иҗатының нигезенә кайгылы яки көлкеле вакыйга салынган, шул вакыйга тәэсирендә герой күңелендә туган хис-кичерешләрне бәян иткән лиро-эпик жанры.* Бу билгеләмә нинди жанрга туры килә? (2 балл):

Җавап: ____________________

11. Равил Фәйзуллинның «Туган тел турында бер шигырь» яки Газинур Моратның «Туган тел» шигырьләренең жанры (1 балл):
1) күңел лирикасы
2) гражданлык лирикасы
3) сюжетлы шигырь

12. Поэма жанрына карый (1 балл):
1) Равил Фәйзуллин «Сәйдәш» яки Һади Такташ «Мокамай»
2) Гадел Кутуй «Сагыну» яки Габделхәй Сабитов «Ярсулы яз»
3) Хәсән Туфан «Агыла да болыт агыла» яки Сибгат Хәким «Әнкәй»

13. Габделхәй Сабитовның «Тәүге соклану» яки Ш.Камалның «Буранда» әсәрләре нинди жанрга карый? (2 балл):

Җавап: ____________________

14. Ибраһим Газиның «Ак сирень» хикәясендә Сания яки Галимҗан Гыйльмановның «Язмышның туган көне» повестенда Зөһрә образлары кеше образларының кайсы төренә карый? (2 балл):

Җавап: ___________________

15. «Бу кырлар, бу үзәннәрдә» шигыренең авторы (2 балл):

Җавап: ___________________

**II бүлек. Биремнәрне үтәгез (16 балл).**

1. Билгеләнгән урыннарга әдипнең, әсәрнең исемен һәм жанрын язып куегыз (6 балл):

_____________________________________________ – иҗат юлын әдәбиятчы һәм әдәби тәнкыйтьче буларак башлаган язучы. Аның исеме матбугатта 1960 елларда күренә башлый. 1967 елда «Казан утлары» журналында аның берничә кыска хикәясе басылып чыга. Ә тагын бер елдан шул ук журнал битләрендә язучының Бөек Ватан сугышы чорының авыр шартларында Арча педагогия училищесында укучы яшүсмерләрнең көндәлек тормышын, дөньяны танып белергә өйрәнүләрен кызыклы ситуацияләр аша тасвирлаган «______________________________________________________» исемле беренче ______________________________ басылып чыга.

2. Габделхәй Сабитовның «Ярсулы яз» әсәреннән алынган әлеге юллардан 3 тел-сурәтләү чарасын табып языгыз. Аларның һәрберсе нинди функция үти дип уйлыйсыз? Җавабыгызны мисаллар белән дәлилләп, аңлатып языгыз (6 балл):

«*...Көлеп арыгач, кар йомарлап, Гамилнең башына тондырды да ак бәкәлле колын кебек сикерә-сикерә китеп барды... Өйдә яз галәмәтләре. Ике тәрәзә арасында кышның кыш буе хәрәкәтсез яткан күбәләккә дә яз кояшы җан өргән. Ул кара бәрхет канатларын лепелдәтеп очарга талпына...».*

3. Ренат Харисның «Кеше кайчан матур?» шигыреннән алынган әлеге өзекнең төп фикере нинди? (Җавабыгызны төгәл языгыз) (4 балл):

...Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул вакыт –
иле өчен, халкы өчен
яшәгәндә җан атып;

замананың авырлыгын
җилкәсенә алганда;
олы данга ирешеп тә,
кече булып калганда.

**III бүлек. Фатих Кәримнең «Кыр казы» шигыренә анализ (14 балл).**

**Шигырьне укып, түбәндәге сорауларга җавап языгыз.**

1. Шигырьнең лирик героена характеристика бирегез. Аңа нинди сыйфатлар хас? (**5 балл**)

2. Лирик геройның хис-кичерешләрен җиткерү өчен шагыйрь нинди образлардан файдалана? Алар аркылы нинди фикерләр әйтергә тели? (**5 балл**)

3. Шигырьгә карата үзегезнең шәхси мөнәсәбәтегезне җиткерегез (шигырь сездә нинди хис-тойгылар, фикерләр уятты, нәрсәләр турында уйланырга этәрде?) (**4 балл**).

## VIII СЫЙНЫФ

**I бүлек. Тест биремнәренә җавап языгыз (25 балл).**

1. Дастан жанрына караган әсәрне билгеләгез (1 балл):

1) «Нәсыйхәт»
2) «Йөзек кашы»
3) «Идегәй»

2. Яшәүнең мәгънәсен эзләүче ялгыз кеше фаҗигасе үзәккә куелган агым (1 балл):

1) реализм
2) сызлану фәлсәфәсе
3) романтизм

3. Әдәби образ тудыруда катнаша торган (гомумән, әдәби әсәрдәге әйберләр дөньясын хасил итүче) аеруча әһәмиятле, аерып чыгарылган элементлар, әйбер, сызык, хәрәкәт, төс, күренешләр (1 балл):

1) символ
2) деталь
3) портрет

4. Уртак мәгънәләрне белдергән, кимендә ике мәгънәне үзенә туплаган шартлы образ (1 балл):

1) символ
2) әйбер образлары
3) шартлылык

5. *Халык авыз иҗатында эпик характердагы, гадәттә әкият сюжетларын, риваять-легендаларны әдәби эшкәртеп язылган әсәр, формасы белән тезмә яки чәчмә булырга мөмкин.* Бу билгеләмә кайсы жанрга карый? (2 балл):

Җавап: ____________________

6. Кешенең эчке дөньясын ачуга хезмәт итә торган алымнар берлеге, геройның эчке халәтен, кичерешләрен сурәтләү (2 балл):

Җавап: ____________________

7. Кешенең тышкы кыяфәтен, йөз төзелешен, буй-сынын һәм үз-үзен тотышын, сөйләмен тасвирлау (2 балл):

Җавап: ____________________

8. Әдәби әсәрдә табигать, авыл, шәһәр күренешләре, вакыйга барган тирәлекне тасвирлау (2 балл):

Җавап: ____________________

9. Хатлар рәвешендә язылган әсәрләр нинди стильгә карый? (2 балл):

Җавап: ____________________

10. Тарихи вакыйгаларны үзәккә алган, тарихи шәхесләр белән бәйле вакыйгаларны сурәтләгән роман төре (2 балл):

Җавап______________________________________

11. Шәриф Камалның «Буранда» яки Әмирхан Еникинең «Кем җырлады?» хикәяләрендә Мостафаның яки лейтенант егетнең эчке дөньясын, кичерешләрен сурәтләүдә нинди алым кулланыла (1 балл):

1) психологик анализ
2) романтик алымнар
3) сызлану фәлсәфәсе

12. Аяз Гыйләҗевның «Язгы кәрваннар» яки Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» әсәрләре эпик төрнең кайсы жанрына карый? (2 балл):

Җавап______________________________________

13. Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендәге Әлмәндәр яки Фәнис Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» әсәрендәге Фәнияр образлары кеше образларының кайсы төренә карый? (2 балл):

Җавап: ____________________

14. Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» яки Фәнис Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестьларының жанр формасы (2 балл):

Җавап: ____________________

15. «Җидегән чишмә» романының авторы (2 балл):

Җавап: ____________________

**II бүлек. Биремнәрне үтәгез (16 балл).**

1. Билгеләнгән урыннарга әдипнең, әсәрнең исемен һәм жанрын язып куегыз (6 балл):

__________________________________________________ сугыш алды прозасында тормышны артык бизәп, аның бары яхшы якларын гына күрсәтү чагыла. 1935 елда «Совет әдәбияты» журналында аның Галия һәм Искәндәр белән бәйле вакыйгаларны сурәтләгән «_____________________________________________» исемле __________________ басылып чыга. 1944 елда ул улы Рөстәмгә багышлап, «Рөстәм маҗаралары» дигән маҗаралы-фантастик повестен яза.

2. Аяз Гыйләҗевның «Язгы кәрваннар» әсәреннән алынган әлеге юллардан 3 тел-сурәтләү чарасын табып языгыз. Аларның һәрберсе нинди функция үти дип уйлыйсыз? Җавабыгызны мисаллар белән дәлилләп, аңлатып языгыз (6 балл):

«*...Җанны өшетә торган салкын коры кич килде.*

*Төш авышуга зират тавыннан өзлексез җил исә башлады. Битләрне аяусыз чеметеп, кием-салымнарны әрсез йолыккалап, туктаусыз коры салкын җил исте, суытты, көн ямьсезләнде. Карт-корылар тиз үк мичләргә ягып җибәрделәр, җил үтәрдәй араннарда калган мал-туарны җылы абзарларга куып керттеләр...».*

3. Равил Фәйзуллинның «Балачак» дип аталган әлеге берьюллыгының төп фикере нинди? (Җавабыгызны төгәл языгыз) (4 балл):

*Җил бик тиз актарды әкият китабын*.

**III бүлек. Фатих Кәримнең «Бездә яздыр» шигыренә анализ (20 балл).**

**Шигырьне укып, түбәндәге сорауларга җавап языгыз.**

1. Шигырьнең лирик героена характеристика бирегез. Аңа нинди сыйфатлар хас? (**5 балл)**

2. Лирик геройның хис-кичерешләрен җиткерү өчен шагыйрь нинди образлардан файдалана? Алар аркылы нинди фикерләр әйтергә тели? (**5 балл**)

3. Шигырьнең темасын (әсәр нәрсә турында?) һәм идеясен (язучы нәрсә әйтергә тели?) ачыклап языгыз (**6 балл**).

4. Шигырьгә карата үзегезнең шәхси мөнәсәбәтегезне җиткерегез (шигырь сездә нинди хис-тойгылар, фикерләр уятты, нәрсәләр турында уйланырга этәрде?) (**4 балл**).

## IX СЫЙНЫФ

**I бүлек. Тест биремнәренә җавап языгыз (25 балл).**

1. Татар әдәбияты тарихының чорлары дөрес эзлеклелектә бирелгән вариантны сайлагыз (1 балл):

1) Алтын Урда чоры әдәбияты – Гомумтөрки әдәбият – Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты

2) Гомумтөрки әдәбият – Алтын Урда чоры әдәбияты – Болгар чоры әдәбияты

3) Гомумтөрки әдәбият – Урта гасыр әдәбияты – Яңа заман әдәбияты

2. Муса Җәлил иҗат иткән «Җырларым» әсәренең жанры (1 балл):

1) гражданлык лирикасы
2) күңел лирикасы
3) фәлсәфи лирика

3. Борынгы төрки язма истәлекләргә карый (1 балл):

1) Кол Гали «Кыйссаи Йосыф»
2) Кол Шәриф «Гафил торма»
3) Мәхмүд Кашгарый «Диване лөгатет-төрк»

4. Барлыкка килгәннән алып язуда беркетелгән әсәрләр җыелмасы (1 балл):

1) архетип
2) язма әдәбият
3) әдәбият тарихы

5. Әдәбиятның билгеле бер тарихи вакыт аралыгындагы хәрәкәте, үсеш-үзгәреше (2 балл):

Җавап: ____________________

6. Кешене аң-белемгә өндәгән, югары идеалларга хезмәт итәргә чакыруга йөз тоткан, мәгърифәтле геройны үзәккә куйган реалистик иҗат методы (2 балл):

Җавап: ____________________

7. Кешенең эчке дөньясын – хис-кичерешләрен, аның үсеш-үзгәрешен, уй-фикерләрен, мөнәсәбәтен сурәтләү объекты итеп күтәргән әдәби төр (2 балл):

Җавап: ____________________

8. Драма төренең юмористик яки сатирик пафоска нигезләнгән, тормыш-көнкүрештәге, аерым кешеләр характерындагы кимчелекле яклардан көлеп язылган жанры (2 балл):

Җавап: ____________________

9. Дини кыйммәтләрне югары күтәргән, ислам динендә макталган сыйфатлар турында сөйли торган әдәбият. Бу сыйфатлар «дини әдәбият» яки «суфичылык әдәбияты» төшенчәләренең кайсына туры килә? (2 балл):

Җавап: ____________________

10. Әдәби әсәрнең өлеш-компонентларын билгеле бер тәртиптә урнаштыру, әдәби форманың төзелеш-структурасы (2 балл):

Җавап______________________________________

11. Сәйф Сараи иҗаты әдәбиятның кайсы чорына карый? (1 балл):

1) XX йөз башы
2) Болгар чоры
3) Алтын Урда чоры

12. Урта гасыр татар әдәбиятында киң таралган мәхәббәт шигыре (2 балл):

Җавап______________________________________

13. Фоат Садриевның «Таң җиле» романындагы Нуриасма яки Туфан Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» драмасындагы Нурислам образлары кеше образларының кайсы төренә карый? (2 балл):

Җавап: ____________________

14. Әмирхан Еники «Ана һәм кыз» яки Айгөл Әхмәтгалиева «Кайтаваз» әсәрләренең жанры (2 балл):

Җавап: ____________________

15. «Гыйлемнең өстенлеге турында», «Горбәтнамә» әсәрләренең авторы (2 балл):

Җавап: ____________________

**II бүлек. Биремнәрне үтәгез (20 балл).**

1. Билгеләнгән урыннарга әдипнең, әсәрнең исемен һәм жанрын язып куегыз (6 балл):

_________________________ – XX йөз башы татар прозасының танылган прозаигы, тәнкыйтьчесе. 1911 елда ул татар әдәбиятының таҗы булган «__________________» _________________ яза. Г.Ибраһимов язганча, «монда Лизаның бакчасында әллә ничаклы яшьләр җыела; монда бар Борһан абзый гаиләсе: монда бар Гыймадовлар гаиләсе...».

2. Фоат Садриевның «Таң җиле» романыннан алынган әлеге юллардан 3 тел-сурәтләү чарасын табып языгыз. Аларның һәрберсе нинди функция үти дип уйлыйсыз? Җавабыгызны мисаллар белән дәлилләп, аңлатып языгыз (6 балл):

«...*Читтән караганда, аны фәрештә дип уйларга мөмкин иде: кардай ак озын күлмәк, кардай ак яулык астыннан чыккан кардай ак чәчләр күренеп тора... Әнә ул, ак фәрештә сыман, ямь-яшел Ык буена килеп басты. Нуриасма башын бераз күтәрде дә, карашын Ык аръягы өстеннән йөгертеп, еракка – зәңгәрсу өрфия артында күкләргә ашып торучы Чия тавына юнәлтте... Кояшның алтын бишеге тау итәгенең әнә шул бил турысына асылгандыр кебек тоела Нуриасмага*».

3. Зөлфәтнең «Тылсым» дип аталган шигыреннән алынган өзекнең төп фикере нинди? (Җавабыгызны төгәл языгыз) (3 балл):

*Изсәләр дә, кылыч чапсалар да,*
*Юлыкса да юлда мең үткел,*
*Шигырьле тел – фанилыкка бәйсез*
*Үлемгә баш бирми андый тел*.

4. Аяз Гыйләҗевның «Өч аршын җир» повестендагы Шәмсегаян яки «Җомга көн, кич белән» әсәрендәге Бибинур образына характеристика

бирегез. Җавабыгызны үзегез теләгән БЕР әсәр нигезендә дәлилләп языгыз (5 балл):

**III бүлек. Муса Җәлилнең «Соңгы җыр» шигыренә анализ (20 балл).**

**Шигырьне укып, түбәндәге сорауларга җавап языгыз.**

1. Шигырьнең лирик героена характеристика бирегез. Аңа нинди сыйфатлар хас? (**5 балл**)

2. Лирик геройның хис-кичерешләрен җиткерү өчен шагыйрь нинди образлардан файдалана? Алар аркылы нинди фикерләр әйтергә тели? (**5 балл**)

3. Шигырьнең темасын (әсәр нәрсә турында?) һәм идеясен (язучы нәрсә әйтергә тели?) ачыклап языгыз (**6 балл**).

4. Шигырьгә карата үзегезнең шәхси мөнәсәбәтегезне җиткерегез (шигырь сездә нинди хис-тойгылар, фикерләр уятты, нәрсәләр турында уйланырга этәрде?) (**4 балл**).

## X СЫЙНЫФ

**I бүлек. Тест биремнәренә җавап языгыз (25 балл).**

1. Эпик жанрларның үсә бару тәртибе дөрес эзлеклелектә бирелгән вариант (1 балл):

1) повесть, нәсер, хикәя
2) хикәя, повесть, роман
3) хикәя, роман, кыйсса

2. Тормышның (шәхси, иҗтимагый) аерым бер якларын тәнкыйтьләп көлүгә, кире кагуга, мыскыл итүгә корылган пафос төре (1 балл):

1) сатирик
2) комик
3) тәнкыйди

3. 1920-30 еллар әдәбиятына карый (1 балл):

1) Фатих Әмирхан «Шәфигулла агай» яки Гаяз Исхакый «Җан Баевич»
2) Фатих Әмирхан «Шәфигулла агай» яки Әмирхан Еники «Ана һәм кыз»
3) Гаяз Исхакый «Җан Баевич» яки «Остазбикә»

4. Әдәби-эстетик агым, шәхеснең рухи иреген, фикер хөрлеген яклап баш күтәрү (1 балл):

1) романтика
2) конфликт

3) гыйсъянчылык

5. Әсәрнең эмоциональ көйләнеше, яңгырашы, аһәңе (2 балл):

Җавап: ____________________

6. Тормышның бер кечкенә өзеге аша кеше характерларын ачуга корыла, хәзер бара торган хәлләрне сәхнәдә уйнау кебек иҗат ителә. Бу сыйфатлар әдәбиятның кайсы төренә хас? (2 балл):

Җавап: ____________________

7. Язучының әсәрләрен башка язучылардан аерып торган үзенчәлекләр: тел-сурәтләү чараларын куллану, фикерне белдерү, образ төзү – тасвирлау алымнары (2 балл):

Җавап: ____________________

8. Төп герой тормышындагы берничә охшаш яки каршылыклы хәл, вакыйгалар тезмәсе сурәтләнгән, берничә сюжет сызыгы бер үзәк тирәсенә берләшкән эпик жанр (2 балл):

Җавап: ____________________

9. Лирик герой яки хикәяләүченең укучыга, әсәрдә сурәтләнгән образга эндәшүе (2 балл):

Җавап: ____________________

10. Әдәби әсәрдә тасвирланган вакыт һәм урын (2 балл):

Җавап______________________________________

11. Башка авторның теге яки бу әсәре тәэсирендә туган, аңа охшатып язылган әсәр (1 балл):

1) күчермә
2) традиция
3) нәзыйрә

12. Сүз сәнгатендә тупланган тәҗрибәне буыннан-буынга күчерү (2 балл):

Җавап______________________________________

13. Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» драмасындагы Ана яки Галимҗан Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романындагы Зыя образы кеше образларының кайсы төренә карый? (2 балл):

Җавап: ___________________

14. Гаяз Исхакыйның «Остазбикә» яки «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрләренең жанры (2 балл):

Җавап: ___________________

15. «Кыйтга», «Өзелгән өмид» шигырьләренең авторы (2 балл):

Җавап: ___________________

**II бүлек. Биремнәрне үтәгез (20 балл).**

1. Билгеләнгән урыннарга әдипнең, әсәрнең исемен һәм жанрын язып куегыз (6 балл):

1913 елда «Эч пошканда», «Яз әкиятләре», «Битлек», «Серле-серле әкият» хикәяләрен иҗат итеп, әдәби эшчәнлеген башлаган _________________________ 1921 елда «___________________» _________________ яза. Һәрбер хикәясендә төрле фәлсәфи мәсьәләләр күтәргән әдип бу әсәрендә дә төп фикерне сюжет ярдәмендә түгел, ә фәлсәфи фикер һәм психологик катлам аша җиткерә. Әсәрнең төп герое – Ильяс, 1914 елның языннан алып көзенә кадәр Идел елгасы янында барган вакыйгалар аның исеменнән хикәяләнә.

2. Гаяз Исхакыйның «Көз» повестеннан алынган әлеге юллардан 3 тел-сурәтләү чарасын табып языгыз. Аларның һәрберсе нинди функция үти дип уйлыйсыз? Җавабыгызны мисаллар белән дәлилләп, аңлатып языгыз (6 балл):

«*...Күзенә яшь тыгылды. Шуны куәтләгән кебек, урман өстеннән бер җил үтте. Шайтан туе, сары яфраклар, сары саламнар, иске тузаннарны җыеп, Гөлсемнәрне куа иде, аларны җитәм-җитәм дип ашыга иде. Менә тагы җил, тагы бер өермә, әнә аларның өстенә сары яфраклар, көзге яфраклар оча... Көзге вак яңгыр акрын гына сибәли башлады...*».

3. Равил Фәйзуллинның «Туган тел турында бер шигырь» дип аталган шигыреннән алынган өзекнең төп фикере нинди? (Җавабыгызны төгәл языгыз) (3 балл):

*Күп телләрне белү – яхшы шөгыль,*
*туган телең үги калмаса.*

*Җанын салып әйткән әткәң сүзен*
*синең аша балаң аңласа*.

4. Гаяз Исхакыйның «Остазбикә» әсәрендәге Сәгыйдә яки «Көз» повестендагы Нәфисә образына характеристика бирегез. Җавабыгызны үзегез теләгән БЕР әсәр нигезендә дәлилләп языгыз (5 балл):

**III бүлек. Муса Җәлилнең «Яулык» шигыренә анализ (20 балл).**

**Шигырьне укып, түбәндәге сорауларга җавап языгыз.**

1. Шигырьнең лирик героена характеристика бирегез. Аңа нинди сыйфатлар хас? (**5 балл**)
2. Лирик геройның хис-кичерешләрен җиткерү өчен шагыйрь нинди образлардан файдалана? Алар аркылы нинди фикерләр әйтергә тели? (**5 балл**)
3. Шигырьнең темасын (әсәр нәрсә турында?) һәм идеясен (язучы нәрсә әйтергә тели?) ачыклап языгыз (**6 балл**).
4. Шигырьгә карата үзегезнең шәхси мөнәсәбәтегезне җиткерегез (шигырь сездә нинди хис-тойгылар, фикерләр уятты, нәрсәләр турында уйланырга этәрде?) (**4 балл**).

## XI СЫЙНЫФ

**I бүлек. Тест биремнәренә җавап языгыз (25 балл).**

1. Язучы иҗатында яисә әдәби әсәрдә эзлекле кабатлана торган мотив (1 балл):

1) тема
2) мотив
3) лейтмотив

2. Гражданлык лирикасында лирик геройга хас үзенчәлек (1 балл):

1) бер төркем, милләт, иҗтимагый катлау вәкиле булып, шулар исеменнән сөйли
2) табигатькә гашыйк лирик герой
3) яшәешне күзәтүче, тормыш-яшәеш кануннары турында уйланучы, шуның камил булмавыннан ризасыз кеше, ялгыз шәхес, философ

3. Сугыш чоры татар әдәбиятында актив булган эпик жанр (1 балл):

1) гражданлык лирикасы
2) хикәя
3) драма

4. Бөек Ватан сугышы чоры әдәбиятына карый (1 балл):

1) Фатих Хөсни «Йөзек кашы»
2) Фәүзия Бәйрәмова «Канатсыз акчарлаклар»
3) Зөлфәт Хәким «Гасыр моңы»

5. Язучы сөйләменә, язу рәвешенә хас үзенчәлекләрне яктырткан стиль төре (2 балл):

Җавап_______________________________________

6. Яшәешнең, кеше табигатенең асылын төгәл, дөрес итеп гәүдәләндерүче иҗат юнәлеше (тибы) (2 балл):

Җавап: ____________________

7. Кечкенә күләмле, эмоциональлеге, ритмик төзелеше белән шигъри сөйләмгә якын булган һәм хис-кичерешнең үсеш-үзгәрешен күрсәтә торган чәчмә әсәр (2 балл):

Җавап: ____________________

8. Персонажларның трагик каршылыгына нигезләнгән һәм, гадәттә, фаҗига белән тәмамлана торган драма жанры (2 балл):

Җавап: ____________________

9. Мәгънә ягыннан капма-каршы булган төшенчә яисә образларны белдерүче стилистик фигура (2 балл):

Җавап: ____________________

10. Лирик әсәрдә уй-хисләре, эчке халәте чагылыш тапкан, шагыйрьнең хисләреннән тыш, күпчелек кешеләргә хас уй-кичерешләрне гәүдәләндерүче, бәян итүче образ  (2 балл):

Җавап_______________________________________

11. Бөек Ватан сугышы чоры татар әдәбиятына хас үзенчәлек (1 балл):
1) сугыш темасының алга чыгуы, кечкенә жанрларга өстенлек бирү, солдат белән бәйле вакыйгаларны, хис-кичерешләрне сурәтләү
2) тылдагы тормыш турында гына язу, кечкенә жанрларга өстенлек бирү, хатын-кыз азатлыгы, кадимчелек проблемасының алга чыгуы
3) сугыш темасының активлашуы, аң-белем, тәрбия проблемаларына игътибар юнәлтү, кечкенә жанрларга өстенлек бирү

12. Мәгънәне, идеяне символ-билге аша белдерүче әдәби агым (2 балл):

Җавап____________________________________

13. Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повестендагы йөзек яки Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасындагы йолдыз образы ясалма образларның кайсы төренә карый? (2 балл):

Җавап: ____________________

14. Нәбирә Гыйматдинованың «Сихерче» яки «Ак торна каргышы» әсәрләренең жанры (2 балл):

Җавап: ____________________

15. «Болын», «Канатсыз акчарлаклар» повестьларының авторы (2 балл):

Җавап: ____________________

**II бүлек. Биремнәрне үтәгез (20 балл).**

1. Билгеләнгән урыннарга әдипнең, әсәрнең исемен һәм жанрын язып куегыз (6 балл):

Язучы-прозаик буларак ______________________________________ исеме матбугатта 1960 еллар ахырында күренә башлый. 1968 елда «Казан утлары» журналында аның «Без – кырык беренче ел балалары» исемле беренче повесте басылып чыга. Язучының «_____________________________________» дип аталган __________________ сугыш чорын тасвирлаган башка әсәрләрдән аерылып тора. Татар халкының тормышын, яшәү рәвешен шактый киң планда чагылдырса да, сурәтләү өчен, автор гадәти, гап-гади Кара Чыршы авылын сайлап ала. Әсәр сугышның үзе турында түгел, сугыш чоры турында гына да түгел, ул сугышның авыл халкына алып килгән афәте һәм шул афәтне җиңеп чыга алган намуслы кешеләр турында. Әсәрнең сюжеты Шәяхмәт карт гаиләсе белән бәйле вакыйгаларны тасвирлый.

2. Илдар Юзеевның «Гашыйклар тавы» әсәреннән алынган әлеге юллардан 3 тел-сурәтләү чарасын табып языгыз. Аларның һәрберсе нинди функция үти дип уйлыйсыз? Җавабыгызны мисаллар белән дәлилләп, аңлатып языгыз (6 балл):

«*...Таллыкүл буйларына чыгарга теләп, магнитофон эчендә һәм минем йөрәгемдә, яралы кош сыман, бер җыр канат кагына. Соң чиккә кадәр тыелып-тыелып килдем дә канатлары каерылган, туган туфрагыннан*

*аерылган ул сагышлы җырны туган җиренә очырдым. Сәет аганың җәрәхәтләнгән, үзеннән бәхетлерәк җыры Таллыкүлгә кайтып егылды...».*

3. Илдар Юзеевның «Тормыш ул серле бер могҗиза» дип аталган шигыреннән алынган өзекнең төп фикере нинди? (Җавабыгызны төгәл языгыз) (3 балл):

*Бәхетле минутлар, бәхетсез сәгатьләр –*
*Барысы да мизгелдәй тиз уза.*
*Нурыңны коеп кал, гомереңне тоеп кал,*
*Тормыш ул – серле бер могҗиза.*

4. Зөлфәт Хәкимнең «Гасыр моңы» әсәрендә моң образы нинди вакыйгалар белән бәйләнгән, нәрсәне аңлатып килә? Җавабыгызны әсәр сюжетына нигезләнеп языгыз (5 балл):

**III бүлек. Муса Җәлилнең «Сөеклемә» шигыренә анализ (20 балл).**

**Шигырьне укып, түбәндәге сорауларга җавап языгыз.**

1. Шигырьнең лирик героена характеристика бирегез. Аңа нинди сыйфатлар хас? (**5 балл**)
2. Лирик геройның хис-кичерешләрен җиткерү өчен шагыйрь нинди образлардан файдалана? Алар аркылы нинди фикерләр әйтергә тели? (**5 балл**)
3. Шигырьнең темасын (әсәр нәрсә турында?) һәм идеясен (язучы нәрсә әйтергә тели?) ачыклап языгыз (**6 балл**).
4. Шигырьгә карата үзегезнең шәхси мөнәсәбәтегезне җиткерегез (шигырь сездә нинди хис-тойгылар, фикерләр уятты, нәрсәләр турында уйланырга этәрде?) (**4 балл**).

# ОЛИМПИАДАГА ӘЗЕРЛӘНҮ ӨЧЕН ЯРДӘМЧЕ ӘДӘБИЯТ

Әдәби нурлар: 4 кисәктә / Н.М. Йосыпова, Р.Ә. Абдуллина. – Казан: Татар балалар нәшрияты, 2025.

Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / Д.Заһидуллина, В.Р.Әминева, М.И.Ибраһимов, Н.Йосыпова, Ә.М.Закирҗанов, Т.Гыйләҗев, Г.Р.Гайнуллина. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

Есин А. Принципы и приемы анализа литературного произведения / Есин А. – М.: Флинта, Наука, 2002. – 248 с.

Заһидуллина Д. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы / Д.Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2004. – 367 б.

Заһидуллина Д. Татар әдәбияты. Теория. Тарих / Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов, Н.Йосыпова, Т.Гыйләҗев. – Казан: Мәгариф, 2006. – 364 б.

Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек. – Казан: Казан университеты, 2011. – 1 нче китап: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – 230 б.

Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек. – Казан: Казан университеты, 2011. – 2 нче китап: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

Заһидуллина Д. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111 б.

Интерактивные озвученные электронные таблицы по изучению татарского языка и литературы «Тамыр / Тамырлар» / Н.М. Юсупова // https://apps.apple.com/me/app/%D1%82%D0%B0%D0%BC%D1%8B%D1%80-%D0%BB%D0%B0%D1%80/id6480413847

Татар әдәбияты таблицаларда / А.Т. Низамиева, Э.В. Әсәдуллина. Фәнни мөхәррир – Н.М. Йосыпова. – Казан: Татар балалар нәшрияты, 2023. – 69 б.

Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т.1. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2021. – 423 б.

Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т.2. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2022. – 462 б.

Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т.3. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2023. – 551 б.

Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т.4. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2023. – 630 б.

Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т.5. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2024. – 575 б.

Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т.6. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2025. – 758 б.

Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т.7. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2019. – 575 б.

Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т.8. – Казан: Фолиант., 2021. – 740 б.

Татарча-русча-инглизчә әдәбият белеме терминнары сүзлекчәсе / Сәйфулина Ф.С., Закирҗанов Ә.М., Минһаҗева Л.И., Йосыпова Н.М., Гайнуллина Г.Р., Гыйлаҗев Т.Ш. – Казан: Казан ун-ты нәшрияты, 2014. – 160 б.

## ЭЧТӘЛЕК

Кереш..........................................................................................................3

Беренче бүлек. Татар әдәбиятыннан олимпиада: биремнәрнең үзенчәлеге һәм әзерләнүгә бәйле методик киңәшләр......................................4

Икенче бүлек. Гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятының республика турыннан олимпиада биремнәре...........................10

Олимпиадага әзерләнү өчен ярдәмче әдәбият..........................................26